Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Советы

## L-3 НОМЕРЛЫ КАРАР

Балык Бистәсе штп. 2020 елның 17 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2010 елның 15 октябрендәге «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә хакында» гы I-4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2010елның 15 октябрендәге I-4 номерлы «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә хакындагы» гы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 22.07. 2013 ел, № XXVII-3, 13.12.2014 ел, № XLII -5; 04.09.2018 XXXIII-10, 01.04.2019 XLI-6 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 12 пунктның 3 пунктчасындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-хезмәт кенәгәсенең төп нөсхәсе һәм (яки) гражданинның хезмәт эшчәнлеге турында белешмә, хезмәт килешүе беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда веб-адрес буенча : http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе
муниципаль районы Башлыгы И.Р.Таҗетдинов